СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2022 ел № 65

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитетының Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- җеназа эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтне оештыру өчен шартлар тудыру, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү, күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү өлешендә ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру өчен шартлар тудыру.

2. Татарстан Республикасы Балтач район Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты белән килешү төзергә;

- әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә 2022 ел һәм 2023-2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында проект эшләргә һәм тәкдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының «Җирлек» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Радик Наиловичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов